Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№22 «16» июнь 2022

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы *Ямбакты* авыл җирлеге Башкарма комитетының *2021 елның 14 декабрендәгы 41 номерлы* карары белән расланган 16 яше тулмаган балигъ булмаганнарга Өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, ТР Спас муниципаль районы Никольское авыл җирлеге башкарма комитеты 2022 елның 31 маендагы протестын карап, ТР Спас муниципаль районы *Ямбакты* авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы *Ямбакты* авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның *14 декабрендәге 41 номерлы* карары белән расланган 16 яше тулмаган балигъ булмаганнарга Өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.2. Гариза белән 16 яшькә җиткән (алга таба - мөрәҗәгать итүче) балигъ булмаган гражданнар мөрәҗәгать итә ала.».

1.2. 2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле оешмалар һәм әлеге Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы экспертлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге".

1.3. Административ регламентны түбәндәге эчтәлекле 3.4.1 бүлек белән тулыландырырга:

«3.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүне алдан ук (актив) режимда күрсәтү очраклары һәм тәртибе

Муниципаль хезмәт күрсәтүне алдан ук (проактив) режимда бирү каралмаган.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбактыавыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Ямбакты авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И.Ә.Гәләвҗетдинов.